СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2022 с. Сарманово № 72

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 51 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районы чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясы, «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм Россия Федерациясендә муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 51 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы чикләрендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2 контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, муниципаль җир контроле өчен индикатив күрсәткечләр әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында күрсәтелгән.».

1.2. «Контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, муниципаль җир контроле өчен индикатив күрсәткечләр» карарына 3 нче кушымтаны расларга (кушымта итеп бирелә);

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының экологик мәсьәләләр һәм инфраструктура үсеше мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин